КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2025 ел, 11 ноябрь | г.Казань | № 930

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 июль, 511 нче, 2014 ел, 5 декабрь, 948 нче, 2016 ел, 4 июль, 457 нче, 2019 ел, 25 июнь, 512 нче, 2021 ел, 21 декабрь, 1261 нче, 2023 ел, 18 гыйнвар, 21 нче, 2023 ел, 30 март, 378 нче, 2023 ел, 23 май, 627 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршында Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү буенча Эксперт советы булдырырга.»;

3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү буенча Эксперт советы турында нигезләмә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибендә:

әлеге Нигезләмәнең 4.6 пункты нигезендә Экспертлар советының яңа составы формалаша.

Экспертлар советы әгъзасының вәкаләтләр вакыты тәмамланганчы Экспертлар советы әгъзаларының алмаштыру Экспертлар советы әгъзасының читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелә. Экспертлар советының яңа әгъзасы кандидатурасы даими Реестр составыннан сайлана. Тавыш бирү нәтиҗәсе беркетмә белән рәсмиләштерелә.»;

5.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Экспертлар советы эшенә гомуми җитәкчелек итә, Экспертлар советы утырышларын һәм, кирәк булганда, эш төркемнәре утырышларын үткәрә, шулай ук Экспертлар советы карарларының үтәлешенә гомуми контрольне гамәлгә ашыра;»

5.5 пунктта «шулай ук» сүзен «шулай ук тышкы» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктның бишенче абзацында «консультацияләр» сүзен «җыелышлар» сүзенә алмаштырырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Эксперт советы һәм эш төркемнәре эшләве турында мәгълүматлар җәмәгатьчелеккә ачык була һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5.10 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү буенча Эксперт советы турында нигезләмәгә кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 11 ноябрь, 930 нчы карары редакциясендә)

Дәүләт идарәсе функцияләре

| Т/с | Коды | Дәүләт идарәсе функциясе исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | 01.01 | Социаль-икътисадый программалаштыру |
| 2. | 01.02 | Дәүләт финанслары белән идарә итү |
| 3. | 01.04 | Архитектура эшчәнлеге белән идарә итү |
| 4. | 01.05 | Шәһәр төзелеше белән идарә итү |
| 5. | 01.06 | Табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү |
| 6. | 01.07 | Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү |
| 7. | 01.08 | Бәяләрне (тарифларны) көйләү |
| 8. | 01.09 | Инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу |
| 9. | 01.10 | Дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны комплекслы озата бару белән идарә итү |
| 10. | 01.11 | Инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү |
| 11. | 01.12 | Фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү |
| 12. | 01.13 | Хезмәт белән идарә итү |
| 13. | 01.14 | Энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү |
| 14. | 01.15 | Цифрлаштыру белән идарә итү |
| 15. | 01.17 | Архив эше белән идарә итү |
| 16. | 01.18 | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан урыны буенча теркәлгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның (яшәү урыны буенча теркәлгән шәхси эшкуарларның) белем бирү эшчәнлеген лицензияләү, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш |
| 17. | 01.19 | Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 18. | 01.20 | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү |
| 19. | 01.21 | Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү |
| 20. | 01.22 | Медицина оешмаларының медицина эшчәнлеге функциясен (башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы медицина оешмаларыннан тыш), фармацевтика эшчәнлеген (федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы дару чаралары һәм даруханә оешмалары тарафыннан күпләп сату оешмалары тарафыннан башкарыла торган эшчәнлектән тыш), наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләрне культивацияләү буенча эшчәнлекне (наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенә кертелгән наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлегенә кертелгән психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше буенча эшчәнлек өлешендә, моңа башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы дару чаралары һәм дару оешмалары тарафыннан күпләп сату алып барыла торган эшчәнлек керми) башкарганда |
| 21. | 02.03 | Юстиция өлкәсендә идарә итү |
| 22. | 03.01 | Сәнәгать белән идарә итү |
| 23. | 03.02 | Авыл хуҗалыгы белән идарә итү |
| 24. | 03.03 | Транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү |
| 25. | 03.04 | Элемтә белән идарә итү |
| 26. | 03.05 | Эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салу |
| 27. | 03.06 | Кулланучылар хокукларын тормышка ашыру, тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны гамәлгә ашыру |
| 28. | 04.01 | Гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү белән идарә итү |
| 29. | 04.02 | Сәламәтлек саклау идарәсе |
| 30. | 04.03 | Мәдәният өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану), төрле диндәге дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга ярдәм итү |
| 31. | 04.04 | Физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә |
| 32. | 04.05 | Мәгариф белән идарә итү |
| 33. | 04.06 | Социаль яклау идарәсе |
| 34. | 04.07 | Дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү |
| 35. | 04.09 | Туризм өлкәсендә идарә итү |
| 36. | 04.10 | Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү |

______________________